ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

______________ с. Верхний Услон ______________

«2018 елга «Югары Ослан районы балалар сәнгать мәктәбе» балаларга өстәмә белем бирү муниципаль бюджет мәгариф учреждениесенең норматив чыгымнарын раслау турында»

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 31 декабрендәге 939 номерлы карары нигезендә «Татарстан Республикасы балаларына өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләрен туристик-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм мәдәни юнәлешле һәм күппрофильле мәгариф учреждениеләрен финанслау нормативларын исәпләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 31 декабрендәге 939 номерлы карары белән

КАРАР БИРӘ:

1. 2018нче елга расларга:

- Югары Ослан муниципаль районы балалар сәнгать мәктәбе» балаларга өстәмә белем бирү муниципаль бюджет мәгариф учреждениесендә өстәмә белем бирү программасын гамәлгә ашыруга беркетелгән норматив чыгымнар;

- Югары Ослан муниципаль районы балаларына өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләрендә балаларга туристик-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешле мәгариф программаларын һәм өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф учреждениеләрен 0,5 күләмендә гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарга карата төзәтмәләр коэффициенты;

2. Югары Ослан муниципаль районының финанс-бюджет палатасында түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

- әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләренең норматив чыгымнары нигезендә Югары Ослан муниципаль районы балаларына өстәмә белем бирү учреждениеләрен финанслауны;

- Югары Ослан муниципаль районы балаларына өстәмә белем бирү учреждениеләренең әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнары чоры дәвамында бер үк вакытта Югары Ослан муниципаль районы балаларына өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын индексацияләү белән бергә, ул хезмәт законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитет җитәкчесе Л.С. Хакимзянов

Әзерләде һәм бастырды
5 экз.:
А. З. Халикова

РАСЛАНДЫ
Югары Ослан муниципаль районы
Башкарма комитетының
2017 ел _______ номерлы карары белән

Югары Ослан муниципаль районының “Яшь туристлар станциясе” муниципаль бюджет мәгариф учреждениесендә һәм Югары Ослан муниципаль районының “Яшь туристлар станциясе” муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесендә 2018 елга өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР

| Өстәмә белем бирү программасының юнәлеше | Территориаль урнашу | Норматив чыгымнар, 1 укучыга бер елга сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | беренче уку елы | икенче уку елы | өченче һәм аннан соңгы уку еллары |
| Сәнгать-эстетик | авыл җирлеге | 5512 | 10208 | 12249 |

Башкарма комитет эшләре белән идарә итүче А.К. Минһаҗева